

# Юбилеегыз белән, Габделхай абый!

2024 елның 11 декабрендә авылыбызның хөрмәтле аксакалы, хезмәт ветераны, районда иң беренче фермерларның берсе, Бәзәкә мәчете шурасы рәисе Набиуллин Габделхай Хикмәт улы 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аның гомер юлы илебез тарихында барлык борылышларны үз эченә ала: сугыш еллары, соңыннан илне торгызу алар җилкәсенә төшә. Базар мөнәсәбәтләре башлангач районда беренчеләрдән булып башкаларга үрнәк күрсәтеп авыл хуҗалыгында юл сала Габделхай абый. Тормыш иптәше Мәдинә апа белән 5 бала үстереп олы юлга чыгаралар- алар монда да үрнәк авылдашларга.

Габделхай абыйны авылдашлар, якташлар, сайт укучылары исеменнән олы юбилее белән котлыйбыз! Сау- сәламәт һәм алга таба да барыбызга үрнәк булып, яшьләргә юл күрсәтеп һәм киңәшләрегезне җиткереп, авылыбызга мәчет нурын таратып озак гомер итүегезне телибез!

Түбәндә укучылар игътибарына Габделхай  абыйның истәлекләрен аудиоязмада китерәбез:



*Габделхай абый оныклары белән (сулдан уңга): Гүзәл, Ләйсән, Зилә.*



*Мәдинә һәм Габделхай Набиуллиннар*



*Габделхай һәм Мәдинә Набиуллиннар балалары белән. Басканнар сулдан уңга: Алсу, Раушан, Раушания. Утырганнар: Гөлназ, Мәдинә һәм Габделхай Набиуллиннар, Гөлшат.*



*Габделхай Набиуллинның гаиләсе. Басканнар сулдан уңга: Алсу, Габделхай Набиуллин, Раушан, Раушания. Утырганнар: Гөлназ, Мәдинә Набиуллина, Габделхай абыйның әнисе Маһинур апа, Гөлшат.*



*Габделхай абыйның әтисе Хикмәтулла абзый. 1941 елның августында сугышка китә. 1941 елның азагында Демянск, Старая Русса янындагы сугышларда һәлак була.*